Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

# Б О Е Р Ы К

2014 елның 27 феврале Казан ш. № 40/2-пр

Ведомство максатчан программаларын һәм ведомство максатчан программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыгын үстерү буенча икътисадый әһәмиятле региональ программаларына ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрен раслау турында” 2010 елның 17 декабрендәге 1042 номерлы карары нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәге ведомство максатчан программаларын расларга:

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү”;

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү”;

2. Ведомство максатчан программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә 2014 елда субсидияләр бирү буенча кушымта итеп бирелгән түбәндәге тәртипләрне расларга:

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2014 елда субсидияләр бирү тәртибен (1 нче кушымта);

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2014 елда субсидияләр бирү тәртибен (2 нче кушымта);

3. Тапшырылган документларның дөреслеге, бюджет акчаларының максатчан кулланылуы өчен җаваплылыкны субсидияләрне алучыларга,

агросәнәгать комплексы оешмаларының җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләргә.

4. Бюджет алучы тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген тикшерүне һәм раслауны Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы) Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына йөкләргә.

5. ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы урынбасары С.М. Нигъмәтҗановка, ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы урынбасары Л.В. Павловага һәм ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы И.Ш. Гафуровка әлеге боерыкның 1 пунктында каралган федераль бюджеттан субсидияләр алу өчен тапшырылган документларның ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге, ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге һәм ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге белгечләре тарафыннан кабул итүләрен тәэмин итәргә.

6. ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының финанс бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә әлеге боерыкта билгеләнгән документларда каралган субсидияләрне үз вакытында бирүне тәэмин итәргә.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның урынбасарлары Н.Н. Хаҗиповка һәм И.Х. Габдрахмановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

2014 елның 27 февралендәге 40-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2014 елда субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан программасын (алга таба – Программа) гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2014 елда субсидияләр бирү шартларын регламентлаштыра.

2. Чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр, ит җитештерү күләмнәрен арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудыру максатларында, ит өчен терлек үрчетү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга (алга таба – Программада катнашучылар) бирелә.

3. Субсидияләр ит бирә торган һәм катнаш мөгезле эре терлекне үрчетү белән бәйле Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен гариза нигезендә бирелә.

4. Субсидияләр бирү өчен Программада катнашучыларны сайлап алу критерийлары:

предприятиенең төп эшчәнлек юнәлеше – авыл хуҗалыгы җитештерүе, ит бирә торган һәм катнаш мөгезле эре терлекне үрчетү.

5. Программа чараларын гамәлгә ашыручылар өчен субсидияләр күләме түбәндәгечә билгеләнә:

- 2014 елның 1 гыйнварына булган ит бирә торган токымнарга караган бер баш мөгезле эре терлеккә исәпләгәндә - 5 962,48 сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 2 551,05 сум һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан – 3 411,43 сум;

- 2014 елның 1 гыйнварына булган ит бирә торган токымнар белән кушылган бер баш мөгезле эре терлеккә исәпләгәндә – 2 402,1 сум, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән – 1 035,1 сум һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 367,0 сум.

6. Программада катнашучылар субсидия алу өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр) түбәндәге документлар тапшыралар:

а) 2014 елның 1 гыйнварына исәбе турында белешмәләрне раслау өчен мөгезле эре терлекнең ит бирә торган токымнары һәм ит бирә торган токымнары кушылмалары төркемнәре аерып бирелгән “Фермада терлекнең һәм кош-кортның

әйләнеше турында хисап”ның (форма № СП-51) агросәнәгать комплексы оешмасының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан таныкланган күчермәләре. Нәселле (ит бирә торган) терлек өчен “Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Терлекчелектә нәселлек эше буенча Баш дәүләт авыл хуҗалыгы идарәсе” дәүләт казна учреждениесе тарафыннан таныкланган нәселлек таныклыгы күчермәсе бирелә;

б) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы “а” пунктчасында күрсәтелгән документлар нигезендә субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре.

7. Идарәләр:

а) әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерәләр;

б) Программада катнашучыларга субсидияләр бирү өчен Министрлык тарафыннан расланган форма буенча әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә җыелма исәп-хисап белешмәләрен төзиләр.

8. Министрлык Идарәләр тапшырган документларга нигезләнеп утыз көн эчендә Программа кысаларында субсидияләр алучыларның реестрын раслый.

Программада катнашучылар бюджет акчаларын үзләштермәгән очракта, Министрлык калган лимитларны субсидияләр алучылар реестрына үзгәрешләр кертү юлы белән Программада катнашучылар арасында яңадан бүлергә хокуклы.

9. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны, Министрлык тарафыннан расланган җыелма исәп-хисап белешмәләренә һәм субсидияләр алучылар реестрына нигезләнеп, казна органнарында ачылган үзенең лицевой счетыннан Программада катнашучыларның исәп-хисап счетларына күчерә.

10. Бирелгән субсидияләр, субсидияләр алу өчен Программада катнашучылар тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булса, Министрлыкның тиешле таләбен алган вакыттан алып алтмыш көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияләрне алучылар Тәртипнең әлеге пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча субсидияләрне кайтару срогын бозган очракта, Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок беткән вакыттан алып утыз көн эчендә күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

11. Субсидияләрне алучылар Идарәләргә Министрлык тарафыннан расланган срокларда һәм формалар буенча Программа чараларын тормышка ашыру турында хисаплар тапшыралар.

12. Министрлык Идарәләрдән килгән хисапларны ала һәм субсидияләрне куллану турындагы җыелма хисапларны Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына финанс елы тәмамланганнан соң тапшыра.

13. Программада катнашучылар тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплылык агросәнәгать комплексы оешмаларының җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә.

14. Бүлеп бирелгән акчаларның максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын тикшереп торуны Министрлыкка йөкләргә.

2014 елның 27 февралендәге 40-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

**“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2014 елда субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан программасын (алга таба – Программа) гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2014 елда субсидияләр бирү шартларын регламентлаштыра.

2. Чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр, җитен җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудыру максатларында, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга (алга таба – Программада катнашучылар) бирелә.

3. Субсидияләр гариза нигезендә түбәндәгеләргә бирелә:

җитенне беренче тапкыр эшкәртү объектларын төзү һәм реконструкцияләүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга;

җитенне беренче тапкыр эшкәртү объектлары өчен технологик җиһазлар, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга;

җитен җитештерүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга.

4. Субсидияләр бирү өчен Программада катнашучыларны сайлап алу критерийлары:

предприятиенең төп эшчәнлек юнәлеше – авыл хуҗалыгы җитештерүе, җитен җитештерү һәм эшкәртү.

5. Субсидияләр күләме түбәндәгечә билгеләнә:

җитенне беренче тапкыр эшкәртү объектларын төзү һәм реконструкцияләүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга – башкарылган эшләр күләменең 90 процентына;

җитенне беренче тапкыр эшкәртү объектлары өчен технологик җиһазлар, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга – җиһазлар бәясенең 90 процентына;

җитен җитештерүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга – җитен эшкәртү заводына тапшырылган җитеннең бер мең тоннасына (сүскә күчергәндә) 10,0 мең сум исәбеннән чыгып.

6. Җитенне беренче тапкыр эшкәртү объектларын төзү һәм реконструкцияләүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алу өчен Программада катнашучылар Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм

азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) түбәндәге документлар тапшыралар:

банк тарафыннан расланган түләү йөкләмәсе;

җыелма смета исәп-хисапларының күчермәләре;

төзелеш подряды шартнамәләренең күчермәләре;

КС-2 формасы буенча эшкә кабул итү турында актларның, башкарылган эшләрнең бәясе һәм КС-3 формасы буенча чыгымнар турында белешмәләрнең Программада катнашучы тарафыннан расланган күчермәләре;

КС-2 формасы буенча эшкә кабул итү турында актларның, башкарылган эшләрнең бәясе һәм КС-3 формасы буенча чыгымнар турында белешмәләрнең Программада катнашучы тарафыннан хуҗалыкта эшләр башкарганда расланган күчермәләре;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре.

7. Җитенне беренче тапкыр эшкәртү объектлары өчен технологик җиһазлар, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документлар тапшыралар:

җиһазлар һәм техника китерү буенча шартнамәләр;

товар-транспорт накладнойлары;

счет-фактуралар;

ОС-1 формасы буенча җиһазны кабул итү – тапшыру акты;

банк тарафыннан расланган түләү йөкләмәләре;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре.

8. Җитен җитештерүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документлар тапшыралар:

җитен трестларын китерүгә шартнамәләр;

товар накладнойлары реестры;

кабул итү квитанцияләре;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре.

9. Министрлык таләпләр алынган вакыттан башлап алты ай эчендә, тапшырылган документларга нигезләнеп, субсидияләр алучыларның реестрын раслый.

10. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны, Министрлык тарафыннан расланган җыелма исәп-хисап белешмәләренә һәм субсидияләр алучылар реестрына нигезләнеп, казна органнарында ачылган үзенең лицевой счетыннан Программада катнашучыларның исәп-хисап счетларына күчерә.

11. Бирелгән субсидияләр, субсидияләр алу өчен Программада катнашучылар тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булса, Министрлыкның тиешле таләбен алган вакыттан алып алтмыш көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

12. Субсидияләр бирү турында килешүләрдә (шартнамәләрдә) каралган очракларда хисап финанс елында үзләштермичә калган субсидияләр субсидияләрне

алучы тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

13. Әлеге Тәртипнең 11 һәм 12 пунктларында күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

14. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерәләр.

15. Бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышы һәм Программада катнашучылар тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә агросәнәгать комплексы оешмаларының вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

16. Бүлеп бирелгән акчаларның нәтиҗәле кулланылышын тикшереп торуны Министрлыкка йөкләргә.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ**

# “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү”

**ведомство максатчан**

**программасы**

**Казан 2014**

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” ведомство максатчан программасының

## ПАСПОРТЫ

| **Программаның исеме** | **“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү”** |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы турында” 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасын раслау турында” 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының структур бүлекләре: терлекчелек тармакларын үстерү, инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар, икътисадый анализ һәм планлаштыру, финанслау. |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне булдыру һәм тотрыклы үстерү, сыер итен җитештерүнең конкуренциягә сәләтлелеген арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудыру.<br>Югары сыйфатлы сыер итен җитештерү күләмен арттыру.<br>Ит өчен терлек үрчетү тармагын техник яктан яңадан җиһазлау.<br>Сыер итен куллану дәрәҗәсен арттыру. |
| Төп бурычлар | Билгеләнгән максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:<br>- махсус ит токымнарыннан булган мөгезле эре терлекнең баш санын ел саен 12 процентка |

| | |
|---|---|
| | арттыру;<br>- ит өчен терлек үрчетүнең нәсел базасын ныгыту;<br>- ит җитештерүне арттыру һәм ит өчен терлек үрчетүне тизләтелгән үстерү;<br>- ит куллануны, аның һәркем алырлык булуын һәм халык өчен экологик куркынычсызлыгы дәрәҗәсен арттыру;<br>- авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең заманча технологик җиһазлар, матди ресурслар белән тәэминатын яхшырту. |
| Программада катнашучылар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;<br>“РАСХН Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты” дәүләт фәнни учреждениесе;<br>Ит өчен терлек үрчетү буенча бөтенроссия фәнни-тикшеренү институты (ВНИИМС) Оренбург ш.;<br>“Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе” федераль дәүләт югары һөнәри белем бюджет мәгариф учреждениесе;<br>Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр. |
| Программаны тормышка ашыруның сроклары һәм баскычлары | Программа 2014-2016 елларда тормышка ашырыла<br>Сыер итен җитештерүне шактый арттыру һәм 2016 елда 173,8 мең тоннага җиткерү өчен чаралар өч ел дәвамында гамәлгә ашырылачак. |
| Программаны үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;<br>“РАСХН Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты” дәүләт фәнни учреждениесе;<br>Ит өчен терлек үрчетү буенча бөтенроссия фәнни-тикшеренү институты (ВНИИМС) Оренбург ш.;<br>“Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе” федераль дәүләт югары һөнәри белем бюджет мәгариф учреждениесе;<br>Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр. |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2014-2016 елларда программаны тормышка ашыруга чыгымнарның гомуми күләме 850 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча: 2014 – 267,0 миллион сум, 2015 – 283,0 миллион сум, 2016 – 300,0 миллион сум,<br>- Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән – 340 миллион сум, шулардан еллар буенча:<br>2014 – 107 миллион сум, 2015 – 113,0 миллион сум, 2016 – 120,0 миллион сум,<br>- бюджеттан тыш акчалар исәбеннән 510,0 – миллион сум, шул исәптән еллар буенча:<br>2014 –160,0 миллион сум, 2015 –170,0 миллион сум, 2016 – 180,0 миллион сум. |
| Максат индикаторы һәм | Программаның күрсәткечләре: |

| | |
|---|---|
| программаның күрсәткечләре | - ит бирә торган терлек санын 24,3 мең баштан (2013 елда) 34,0 мең башка кадәр арттыру, шул исәптән сыерларны 10,7 мең баштан 2016 елга 15,3 мең башка кадәр арттыру;<br>- ит бирә торган терлектән югары сыйфатлы ит алуны тере авырлыктагы 2013 елдагы 3,5 мең тоннадан 2016 елда 13,9 мең тоннага кадәр арттыру. |
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр | - Ит бирә торган чиста токымлы һәм катнаш терлектән югары сыйфатлы ит алуны тере авырлыктагы 2013 елдагы 3,5 мең тоннадан 2016 елда 13,9 мең тоннага кадәр арттыру.<br>- Нәселле яшь үгезләрне сатуны 2013 елдагы 100 баштан 2015 елда 300 башка кадәр арттыру.<br>- 2013 елдагы 100 баш сыерга туры килгән 78 баш бозауны 2015 елда 80 башка кадәр арттыру.<br>- Халыкның эш белән тәэминатын арттыру, 122 өстәмә эш урыны булдыру. |
| Идарә итү һәм тикшереп тору системасы | Тулаем программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге җаваплы була. |

## 2. Хәл ителеше программада карала торган проблемаларга характеристика.

Татарстан Республикасының ит өчен терлек үрчетүне үстерүдәге кайбер тенденцияләрне уңай дип әйтеп булмый.

Авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында мөгезле эре терлекнең баш саны кимүгә таба үзгәрә, гәрчә терлекчелектәге төп күрсәткечләрнең уңай динамикасы сакланып калса да, ирешелгән аерым продуктивлык күрсәткечләренең дәрәҗәсе җитәрлек канәгатьләндерерлек түгел. Аерым алганда, 2010-2012 елларда барлык категория хуҗалыкларында ит җитештерү 165,8 мең тоннадан 161,2 мең тоннага кадәр кимеде.

Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының авыл хуҗалыгын үстерүдәге тискәре факторларга түбәндәгеләр керә:

а) базар – авыл хуҗалыгы продукциясенә, шул исәптән иткә, сәнәгать продукциясенә һәм энергия чыганакларына бәяләр диспаритеты. Сәнәгать продукциясенә һәм энергия чыганакларына бәяләр белән авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләр арасында гомер гомергә аерманың зур булуы кимеп кенә калмый, хәтта артуга таба бара. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләренә бәяләрнең аз гына үскәндә, җитештерү өчен кирәкле матди-техник ресурсларга һәм аеруча энергия чыганакларына бәяләрнең динамик артуы күзәтелә, бу нигездә табигый монополияләрнең хезмәт күрсәтүләренә бәяләр һәм тарифлар үзгәрү белән бәйле;

б) макроикътисадый – азык-төлекне импорттан кертү арту шартларында авыл хуҗалыгы продукциясе базарында конкуренция шартлары начарлану;

в) финанс-икътисадый – авыл хуҗалыгын үстерүгә һәм авылны социаль яктан төзекләндерүгә ярдәм итү өчен

бирелә торган федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләменең җитәрлек булмавы;

г) идарә – Россия икътисадын һәм авыл хуҗалыгын үстерүнең региональ аспектларны һәм бюджет күрсәткечләре арасындагы үзара бәйләнешне исәпкә алган озак вакытка исәпләнгән стратегиянең булмавы;

Татарстан Республикасының ит өчен терлек үрчетүне үстерүдәге актуаль проблемаларга түбәндәгеләр керә:

а) структур – институциональ үзгәртеп коруларның акрын баруы, җитештерүне һәм беренчел эшкәртүне оештыру өлкәләрендә эшкуарлыкның кече формаларның, шулай ук авыл хуҗалыгы куллнучылары (эшкәртүче, сатучы (сату-алучы), хезмәт күрсәтүче, тәэмин итүче һәм әзерләүче) кооперативларының начар үсүе;

б) базар – ит бәяләрендәге кискен үзгәрешләр; күпләп сату азык-төлек базарларының үсеш алмавы; конкуренцияне үстерүгә ярдәмнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы; Татарстан Республикасының азык-төлек ягыннан куркынычсызлыгы принципларына таянган авыл хуҗалыгы продукциясен кертү-чыгару сәясәтендәге юнәлешләрнең төгәл билгеләнмәве;

в) финанс-икътисадый – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең финанс ягыннан тотрыксыз булуы, авыл хуҗалыгы оешмаларының инвестицияләрне җәлеп итүчәнлеге түбән булуы, кредит ресурсларын алу кыен булу һәм залог белән тәэминатның җитмәве, җир ресурсларын кадастр бәяләве һәм теркәве процессларының төгәлләнмәве аркасында ипотека кредитлары бирүнең үсеш алмавы; Татарстан Республикасы бюджетының авыл хуҗалыгын үстерүгә һәм авылны социаль төзекләндерүгә ярдәм итү өчен бирелә торган акчаларның күләме чикләнгән булу, шулай ук аларның нәтиҗәле сарыф ителмәве;

г) җитештерү – төп җитештерү фондларының, аларның яңаларын кертү белән чагыштырганда, кими баруы, технологик җиһазларның искерүе; заманча технологияләрнең түбән темплар белән кертелүе;

д) оештыру-идарә һәм кадрлар – идарә итү технологияләрен (бюджетлау нәтиҗәләре буенча идарә итү), мәгълүмат технологияләрен һәм инновацияләрне кертүнең җитәрлек булмавы, идарә итү өлкәсендәге оештыру ягыннан үзгәртеп коруларның озак вакытка сузылуы, квалификацияле идарәче һәм белгеч кадрлар кытлыгы, яшь белгечләрнең китүе;

е) социаль – авыл җирлекләрендәге яшәү шартларының кызыктырырлык булмавы, авыл халкының яшәү дәрәҗәсе югары булмау, социаль инфраструктура (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният) хезмәт күрсәтүләренең сыйфаты начар булу, тууның кимүе, яшьләрнең китүе.

Хәзерге вакытта Россиянең ит һәм ит продуктлары базарлары ресурсларының зур өлеше импорт хисабына формалашуын дәвам итә. Россия өчен азык-төлек куркынычсызлыгын хәл итү нигездә үзебезнең производствоны үстереп үз-үзебезне туклану продуктлары белән тәэмин итүгә кайтып кала. Азык-төлек куркынычсызлыгын хәл итүнең төп чарасы буларак һәрвакыт импортка йөз тоту ил икътисадына зыян китерә: ит импортын сатып алуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә сарыф ителгән миллиардлаган долларлар исә ул үзенең асылы белән ит җитештерүне үстерүгә тотылмаган инвестицияләрне тәшкил итә.

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасы ит өчен терлек

үрчетүне модернизацияләүгә юнәлтелгән. Югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттыру илнең чит илдән кертелә торган иткә бәйлелекне өлешчә булса да киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында ит бирә торган терлек токымнарының баш санын арттыру, аларны асрау һәм ашату технологияләренең камилләштерелүе хисабына аның продуктивлыгын күтәрү, культуралар үстерелә торган көтүлекләрне яхшырту күздә тотыла.

## 2.1 Ит өчен терлек үрчетүне үстерүдәге вәзгыятьне һәм аның мөмкинлекләрен анализлау

Республикада ит өчен терлек үрчетү тармагын үстерү буенча максатчан эшләр алып барыла, ул җирле арзан азыкны кулланып югары сыйфатлы сыер итен җитештерергә мөмкинлек бирәчәк.

Бу – биналар төзүгә һәм механикалаштыру чараларына күләмле булмаган чыгымнар таләп итә торган, югары хезмәт җитештерүчәнлегенә ирешергә мөмкинлек бирә торган тармак. Ул көтүлекләрдән, кыр эшләреннән һәм, концентратлар күп кулланылмаган очракларда, эшкәртү сәнәгатеннән соң калган продукцияне нәтиҗәле файдалана ала. Шулай булса да ит бирә торган терлек яхшы азык, бай туклану белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Бу системаны, беренче чиратта, азыкка зур чыгымнар тотыла торган аз продуктив савым сыерлары булган, сөт җитештерү файдалы булмаган хуҗалыкларга керттеләр.

Ит өчен терлек үрчетүне үстерү чагыштырмача аз капитал салулар һәм аз хезмәт чыгымнары белән югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттыру проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Үзгәргән икътисадый вәзгыять һәм базар икътисадына күчү беренче чиратта, алдагысыннан аермалы буларак, энергия һәм хезмәтне азрак таләп иткән ит өчен терлек үрчетүне үстерүгә нигез бирә. Ит өчен терлек үрчетү технологиясен ресурсларны сак тота торган технологияләргә кертеп карарга була.

Республикада ит бирә торган чиста мөгезле эре терлек токымнарын үрчетүдә махсуслашкан хуҗалыкларның саны 2006 елдан башлап 3 тән 12 гә кадәр арткан.

Ит өчен терлек үрчетү республикада ике юнәлештә алып барыла.

**Беренче юнәлеш** –ит өчен махсуслашкан көтүләр булдыру. 2006-2012 елларда биш нәселле репродукторлар булдырылды.

**Репродуктор хуҗалыкларның токымнар составы**

**1. Саба районы: «Мартен» ҖЧҖ - Лимузин**

**2. Балык Бистәсе районы: «Слободское» ҖЧҖ - Гереформ**
**3. Актаныш районы: «Татарстан» ҖЧҖ - Обрак**
**4. Актаныш районы: «Чиялек» ҖЧҖ - Обрак**
**5. Азнакай районы: «Агро-ТНГС» ҖЧҖ- Герефорд.**

**Икенче юнәлеш** сөт бирә торган сыерларны ит бирә торган токымлы үгезләр белән сәнәгать шартларында кушуны куллanудан гыйбарәт. Бу юнәлеш республикада киңрәк таралган, чөнки бу максатларда аз продуктив сыерларның 30 процентына кадәрен һәр хуҗалыкта кулланырга була. Алга таба катнаш башларның саны арта бару белән йота бара торган кушуны куллану максатка ярашлы була. Беренче буын үгезләрен һәм начаррак таналарны иткә җибәрәләр, ә иң яхшы таналарны көтүгә кушалар. Алар акрын-акрын беренче вакытларда ит көтүләрен тәшкил иткән сөт бирә торган сыерларны алыштыра баралар. Төп көтүгә кушу өчен калдырылган таналарны ит токымын яхшырта торган шундый ук токымлы үгезләр белән каплаттыралар.

Сөт сыерыннан туган бозаулар бары тик ит алу өчен генә кулланыла торган шәхси сектордагы терлекчелектә сәнәгать шартларында кушуны кертү шулай ук өметле. Крестьян (фермер) хуҗалыкларында сыерлар 7-8 яшькә кадәр бозау китерәләр, шуңа күрә беренче 3 – 4 бозауны ит токымы үгезләреннән тудыру, ә калган бозауларны алмаш таналар үстерү өчен сөт үгезләреннән тудыру файдалы була.

## 2.2 Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүнең торышына анализ

| Күрсәткечләр | Санау берәмлеге | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2010 елга карата 2013 ел, процентларда |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә ел ахырына мөгезле эре терлекнең баш исәбе, барлыгы | баш | 807445 | 781551 | 775583 | 739675 | 92 |
| 2. Ит мөгезле эре терлегенең баш исәбе, барлыгы | баш | 31451 | 34389 | 34800 | 24300 | 87 |
| шул исәптән ана башлар | баш | 15538 | 13133 | 17048 | 10700 | 88 |
| 3. Иткә җибәрелә торган ит һәм катнаш мөгезле эре терлеген җитештерү (тере авырлык) | тонна | 3508 | 3666 | 4609 | 3450 | 98 |
| 3. Барлык категория хуҗалыкларда иткә җибәрелә торган сыер итен җитештерү (тере авырлык) | мең тонна | 165,8 | 158,9 | 161,2 | 159,0 | 96 |
| 4. Халыкның җан башына сыер итен җитештерү | килограмм | 43,8 | 41,9 | 42,4 | 41,6 | 95 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. Ит җитештерүнең рентабельлеге<br>- дәүләт ярдәме белән | процент | -21,6 | -21,4 | -16,6 | -24,1 | - |
| - дәүләт ярдәменнән башка | процент | -38,1 | -34,8 | -31,2 | -34,6 | - |

Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү өчен уңай табигый һәм икътисадый шартлар бар. Республикада мөгезле эре терлекнең баш саны шактый зур. Моның өчен тотрыклы азык базасы булдырылган. Икмәк һзм эшкәртү сәнәгате калдыклары күп. Табигый көтүлекләр һәм печәнлекләр арзан азык чыганагы булып торалар, аларның мәйданы 1010 мең гектар яки барлык авыл хуҗалыгы кырларының 22 процентын тәшкил итә.

## 3.0 Төп максатлар һәм бурычлар

Программаның максаты – Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне булдыру һәм аны тотрыклы үстерү һәм сыер итен җитештерүнең конкуренциягә сәләтлелеген арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудыру.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

- 2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттыру һәм ит өчен терлек үрчетүне тизләтелгән үстерү.

- авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрне заманча технологик җиһазлар һәм матди ресурслар; квалификацияле кадрлар белән тәэмин итүне яхшырту.

- Татарстан Республикасы халкын җирле сыйфатлы авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итү, ит куллану дәрәҗәсен күтәрү, аның һәркем алырлык булуы һәм халык өчен экологик куркынычсыз булуы.

- республикага кертелә торган продукцияне алыштыру һәм Татарстан Республикасында җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен экспортка чыгару.

## 3.1 Максат индикаторлары

**Программаның төп максат индикаторлары һәм аларның күрсәткечләре таблицада китерелгән.**

| Күрсәткечләр | Исәпләү берәмлеге | 2013 ел факт | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә ит терлегенең һәм катнаш терлекнең баш саны, шул исәптән: | мең баш | 24,3 | 27,2 | 30,4 | 34,0 |
| а) махсуслаштырылган ит терлегенең баш саны | мең баш | 4,2 | 4,6 | 5,0 | 5,5 |
| шулардан сыер (ана башлар) | мең баш | 1,8 | 2,1 | 2,4 | 2,7 |
| б) катнаш терлекнең баш саны | мең баш | 20,1 | 22,6 | 25,4 | 28,5 |
| шулардан сыер (ана башлар) | мең баш | 8,9 | 10,0 | 11,2 | 12,6 |
| 2. Иткә җибәрелә торган ит һәм катнаш терлекне җитештерү тере авырлыкта | мең баш | 3,5 | 7,3 | 9,6 | 13,9 |
| 4. Ит белән шөгыльләнә торган халыкның санын арттыру | кеше | 24 | 29 | 43 | 50 |

## 3.2 Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы

Программаның төп максатларын хәл итү түбәндәге программа чаралары комплексын эшләү юлы белән башкарыла:

- товар хуҗалыкларында ит һәм катнаш терлекнең ана башларын “сыер – бозау” системасы буенча асрауга ярдәм итү;
- югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттыруга субсидияләр;
- ит репродуктор фермаларын һәм симертү предприятиеләрен технологик модернизацияләүгә ярдәм итү;
- производство объектларын инженер челтәрләргә - газ, җылылык, электрик, су китерү, канализациягә, элемтә челтәрләренә тоташтыру чыгымнарына, шулай ук керү юлларын төзү чыгымнарына субсидияләр;
- азык хәзерләп кую һәм хәзерләү өчен техника һәм җиһазлар сатып алуга субсидияләр;
- көтүлекләрне яхшырту чыгымнарының бер өлешен компенсацияләүгә субсидияләр.

**“Ак Барс” ХК ААЖдә ит өчен терлек үрчетү программасын тормышка ашыру сроклары һәм баскычлары.**

**I баскыч (2012-2013 еллар):**

- ит токымнарын ясый торган үгезләр сатып алу (141 баш);
- аз продуктив сыерларны сайлап алу һәм аларны ит токымлы үгезләр белән орлыкландыру;
- симертү урыннарын (фидлотлар) төзи башлау һәм Программаны тормышка ашыру өчен сайлап алынган агрофирмаларда ана башлар өчен терлекчелек биналарын реконструкцияләү;
- ит юнәлешен җаваплы төп белгечләр белән (технологлар, ветеринарлар, зоотехниклар белән) тәэмин итү.

**II баскыч (2013-2015 еллар):**

- ит өчен терлек үрчетүне үстерү перспективаларын исәпкә алып, көтүлекләргә культуралар чәчү һәм азык булачак орлык әйләнешен оештыру;
- гомуми саны 9 500 булган ана башны үз эченә алган бозаулы ана башлар өчен 19 бүлмә оештыру (булган терлекчелек биналарында)
- гомуми сыйдырышы 25 000 башлык 14 симертү урынын төзү;
- ит белән эш итүчене аерым юридик зат дип карау;
- һәркайсына 200-220 ана баш өчен чиста токымлы нәселле фермалар булдыру;
- булган токымнарның саны буенча нәсел статусын алу;
- проектны дәүләт ярдәме программасына кертү.

**III баскыч (2015-2016 еллар):**

- проектны бөтен көченә эшләтү һәм үзкыйммәтен каплау:

катнаш мөгезле эре терлекнең һәм ит бирә торган токым терлегенең уртача еллык баш саны – **25 000 баш;**

катнаш терлектән һәм ит бирә торган токым мөгезле эре терлегеннән югары сыйфатлы сыер ите җитештерүнең тере авырлыктагы күләмнәре – елына **11,5 мең тонна;**

ит терлекчелеге буенча мөгезле эре терлек итен җитештерүнең гомуми күләме – **елына 12,8 мең тонна** (бракка чыгарылган ана башларны исәпкә алып);

мөгезле эре терлекнең уртача көндәлек артуы - **900 грамм,** шул исәптән симертүдә – кимендә **1 200 грамм.**

- нәселле терлекләрне читкә сата башлау.

## 3.3 Программаның социаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәлелеге

Программаны тормышка ашыру ит терлеген үрчетү һәм симертү белән шөгыльләнә торган предприятиеләрнең тизрәк үсүе өчен терлекне тере авырлыгы 450 кг кадәр һәм аннан да күбрәккә симертүне стимуллаштырып, ит җитештерә һәм симертә торган предприятиеләр булдырып һәм технологик модернизацияләп, техника паркларын яңартып шартлар тудырачак.

Махсуслаштырылган ит терлеге булган терлекчелек предприятиеләрен үстерүгә юнәлтелгән инвестиция проектларын тормышка ашыру 636,0 миллион сум тирәсендә инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк, аның хисабына терлекчелек комплекслары һәм фермаларына реконструкция һәм модернизация башкарылачак. Ит терлегенең баш исәбе 27,3 мең баштан 45,7 мең башка кадәр яки 67 процентка артачак, нәселле ана башларның саны 33,3 процентка артачак һәм 2,4 мең баш тәшкил итәчәк.

Республикада хайваннарның ит өчен продуктивлыгы товар көтүнең генетик потенциалы арту хисабына ел саен 5 процентка артып барачак. 2016 елда ит терлегеннән 13,9 мең тонна (сугымга тере авырлыкта) югары сыйфатлы сыер ите җитештереләчәк. Ит үгезләренең биопродукциясен куллану яхшы икътисадый нәтиҗә бирәчәк. Ит өчен терлек үрчетүгә ярдәм итү махсуслаштырылган предприятиеләрдә яшь терлекне тере массасы 450 килограммга кадәр һәм аннан да күбрәк симертергә мөмкинлек бирәчәк, бу исә югары сыйфатлы сыер итен җитештерү проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, терлекне сәнәгать юлы белән катнаш кушылдыруны стимуллаштырачак.

Азык җыя торган авыл хуҗалыгы техникасын, азык хәзерләү өчен машиналар һәм җиһазлар комплексын сатып алып матди-техник базаны ныгыту предприятиеләрне сыйфатлы азык белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итәргә, ит өчен терлек үрчетүнең җитештерү һәм технологик платформаларын ныгытырга һәм яңартырга мөмкинлек бирәчәк. Тулаем алганда, ит терлегеннән сыер итен җитештерүнең файдасы артачак һәм 8,1 проценттан алып 16,5 процентка кадәр тәшкил итәчәк.

Программаны тормышка ашыру, югары сыйфатлы сыер итен җитештерүне арттырудан һәм әлеге төр ит белән эчке базарны тутырудан тыш, Татарстан Республикасының авыл җире территорияләрендә яңа эш урыннары булдыруны тәэмин итәчәк.

**Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелегенә анализ**

| Күрсәткечләр | Исәпләү берәмлеге | 2013 ел факт | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә ит терлегенең һәм катнаш терлекнең баш саны, шул исәптән: | мең баш | 24,3 | 27,2 | 30,4 | 34,0 |
| ит терлегенең ана башлары | мең баш | 10,7 | 12,1 | 13,6 | 15,3 |
| 2. Барлык төр хуҗалыкларда тере авырлыкта сугымга сыер ите җитештерү | мең баш | 159,0 | 163,8 | 168,7 | 173,8 |
| | процентлар | 100 | 103 | 103 | 103 |
| 3. Ит токымы терлеген һәм аның кушылмасын тере массада сугымга җитештерү | мең баш | 3,5 | 4,0 | 4,5 | 5,1 |
| | процентлар | 96 | 114 | 113 | 113 |
| 4. Сатканда бер баш терлекнең уртача тере массасы | килограмм | 500 | 500 | 500 | 500 |
| 5. Ит белән шөгыльләнә торган халыкның саны арту | кеше | 24 | 29 | 43 | 50 |

Программаның максат индикаторлары һәм аларның икътисадый нәтиҗәлелеге индикаторлары динамикасына анализ нәселле терлекнең исәбен шактый арттыруның һәм югары сыйфатлы сыер итен җитештерү күләмнәрен һәм ит терлегенең гомуми баш исәбен арттыруның мөмкин булуын күрсәтә.

### 3.4. Программа буенча бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелегенә исәп-хисап таблицада китерелгән.

| Күрсәткечләр | | Исәпләү берәмлеге | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 3 елга барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Сыер итен сатудан алынган табыш (ТП) | | миллион сум | 657 | 864 | 1251 | 1113 |
| Сыер итен сатудан алынган табышның еллык артымы (ΔТП) | | миллион сум | 342 | 207 | 387 | 57,5 |
| Программаны финанслау | барлыгы (Ф) | миллион сум | 267 | 283 | 300 | 850 |
| Нәтиҗәлелек күрсәткечләре | $Э_{общ.}$ | процентлар | 128 | 73 | 129 | 6,8 |
| Табыш артымы | | процентлар | 2 тапкыр | 132 | 145 | 190 |

Финанслау акчаларын тоту нәтиҗәлелеге программаның ахыргы нәтиҗәләренең һәм чыгымнарның аны $Э_{общ}$ коэффициенты буенча тормышка ашыруга нисбәте буенча билгеләнә, ул төп индикаторның (бәягә салынган тулаем продуктның) финанслауның гомуми күләменә нисбәтен түбәндәге формула буенча күрсәтә:

$$Э_{общ} = ΔТП/Ф \times 100 \text{ процент},$$

монда:

$Э_{общ}$ – финанс чараларын тотуның гомуми нәтиҗәлелеге коэффициенты;

ΔТП – ит товар продукциясенең бәягә салынган еллык артымы,

Ф – продукцияне җитештерүне финанслау күләме.

### 3.5 Программаның ресурс тәэминатын нигезләү

Программаны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар җәлеп итеп башкарылачак.

Программаның планлаштырылган чараларын тормышка ашыруга кирәк булган акчаларның күләме түбәндәгеләрне исәпкә алып исәпләнә:

- 2012 елда нәселле терлеккә импорт буенча һәм ил эчендәге фактик бәяләрне;
- республика буенча уртача ит сыерларын асрау чыгымнарын;
- ит җитештерүнең республика буенча уртача производство чыгымнарын.

Программаның барлык чараларын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары буенча исәп-хисаплар һәм башлангыч саннар таблицада китерелгән.

**Программа чараларын финанслауга гомуми ихтыяҗ һәм аның чыганаклары, миллион сум.**

| № т/б | Чаралар | Чыганак | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2016-2014 елларга барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Товар хуҗалыкларында сыер белән бозауны асраугa субсидияләр | Татарстан Республикасы бюджеты | 8,8 | 9,3 | 9,9 | 28 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 13,2 | 14,0 | 14,8 | 42 |
| 2 | Яшь терлекне тере массасы 450 кг артыкка симертү чыгымнарын каплауга субсидияләр | Татарстан Республикасы бюджеты | 4,9 | 5,2 | 5,5 | 15,6 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 7,3 | 7,8 | 8,3 | 23,4 |
| 3 | Производство объектларын инженер челтәрләргә - газ, җылылык, электрик, су китерү, канализациягә, элемтә челтәрләренә тоташтыру чыгымнарына, шулай ук керү юлларын төзү чыгымнарына субсидияләр | Татарстан Республикасы бюджеты | 16,4 | 17,3 | 18,3 | 52 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 24,5 | 26,0 | 27,5 | 78 |
| 4 | Ит өчен терлек үрчетү тармагын техник яктан яктан җиһазлау | Татарстан Республикасы бюджеты | 18,3 | 19,3 | 20,6 | 58,2 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 27,4 | 29,1 | 30,8 | 87,3 |
| 6 | Ит репродуктор фермаларын һәм симертү предприятиеләрен төзүгә, техник һәм технологик модернизацияләүгә ярдәм итү | Татарстан Республикасы бюджеты | 58,6 | 61,9 | 65,7 | 186,2 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 87,6 | 93,1 | 98,6 | 279,3 |
| | **Барлыгы:** | Татарстан Республикасы бюджеты | 107 | 113 | 120 | 340 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 160 | 170 | 180 | 510 |
| | | **Барлыгы:** | **267** | **283** | **300** | **850** |

## 3.6 Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасына тасвирлама

Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасы түбәндәгеләр буенча җаваплыларны раслауны күз алдында тота:

- тулаем алганда программаны тормышка ашыру, программа максатларына, бурычларына, максат индикаторларына ирешү, программада расланган бурычлар һәм гамәлләр күрсәткечләре;

- программаны тормышка ашыруда катнаша торган учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләү һәм аларның программа чараларын тормышка ашыру буенча гамәлләрен килештерү;

- Программаның һәр чарасын һәм, шуннан чыгып, программаны тормышка ашыру;

- Программа гамәлләрне финанслау;
- Программаның тормышка ашырылуын мониторинглау;
- Программаны тормышка ашыру барышы турында хисап төзү.

### 3.7 Программа чараларын тормышка ашыру графигы

| № | Программаның бүлекләре, чаралар | Эш күләме | Исәпләү берәмлеге | Үтәлеше өчен җаваплылар | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ит бирә торган токымлы мөгезле эре терлекнең баш исәбен арттыру | 44,7 | мең баш | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы; | 2014-2016 еллар |
| 2 | Азык базасын ныгыту һәм азыкның сыйфатын яхшырту | 500 | гектар | “РАСХН Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты” дәүләт фәнни учреждениесе” ДФУ | 2014-2016 еллар |
| 3 | Ит җитештерүне ел сезоннары буенча тигезләү һәм тотрыклы хәзерләү бәяләренә ирешү максатларында ит базарын җайга салу | 3,8-4,0 | мең тонна | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы; | 2014-2016 еллар |
| 4 | Татарстан региональ институтында эшләүче белгечләрнең ахырдан ит токымнарына керә торган терлекне үрчетү буенча илнең әйдәп баручы нәселле терлек хуҗалыкларында стажировка узу белән бергә квалификациясен күтәрү | 50 | кеше | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2014-2016 еллар |

### 3.8 Ит өчен терлек үрчетүне алып баруның заманча технологияләре буенча белгечләр әзерләүне оештыру һәм аларның квалификациясен күтәрү

| Чаралар | Тормышка ашыру сроклары | Белгечләр саны |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1. Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенең зооинженерлык факультетында студентларны сыер итен сәнәгатьтә җитештерү белгечләре белән бергә әзерләүне оештыру. | 2014-2016 еллар | 30 |
| 2. Татарстан региональ институтында эшләүче белгечләрнең ахырдан ит токымнарына кергә торган терлекне үрчетү буенча илнең әйдәп баручы нәселле терлек хуҗалыкларында стажировка узу белән бергә квалификациясен күтәрү. | 2014-2016 еллар | 70 |
| 3. Хезмәт күрсәтүче персоналның производствода укуын турыдан туры хуҗалыкларда оештыру. | 2014-2016 еллар | 60 |

## 4. "2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү" программасын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү чаралары

1. Татарстан Республикасында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының таләпләренә туры китереп, барлык 43 муниципаль районны территориаль планлаштыру схемалары һәм авыл җирлекләренең генераль планнары эшләнгән. Алар муниципаль берәмлекләренең рәсми сайтларында бар. Алар шулай ук "2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү" программасы колачлаган районнар буенча да бар.

2. 2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү" программасы Татарстан Республикасының барлык 43 муниципаль районында хуҗалык итүнең кече, урта һәм эре формаларының, куллланучылар кооперацияләренең үзара багланышын тәэмин итә.

3. Татарстан Республикасында "2014-2020 елларга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү" Федераль максатчан программасы нигезендә "2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү" программасы эшләнде, анда "2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү" программасы тормышка ашыру урыннарында социаль; инженер һәм транспорт инфраструктураларын үстерү планнары исәпкә алына.

4. Бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында муниципаль районнарда, заманча мәгариф үзәкләрен (база мәктәпләр) төзеп һәм кирәкле мәктәп автобуслары паркын тәэмин итеп, аз комплектлы мәктәпләрнең саны киметелде, республика ел саен мәктәпкәчә балалар учреждениеләрен, гомуми практика табиблары офисларын һәм авылда заманча фельдшер-акушерлык пунктларын, спорт корылмаларын төзүне һәм реконструкцияләүне финанслый.

5. Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан "2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү" программасын үтәү өчен авыл җирлегендә яшәүчеләрнең, шул

исәптән яшь белгечләрнең тормыш шартларын яхшыртуга акчалар бүлеп бирү каралган. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды авыл җирендә торак төзүгә еллык 7 процентлы ипотека кредитлары бирә. “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит өчен терлек үрчетүне үстерү” программасын үтәү өчен торак мәйданы 4,5 мең квадрат метр тәшкил иткән 45 йорт төзү каралган.

6. Татарстан Республикасында авыл инфраструктурасын һәм торак төзелешен үстерүгә “2014-2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” Федераль максатчан программасына өстәп ел саен тагын кимендә 7 миллиард сум бүлеп бирү планлаштырыла.

7. Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджетка караганда артыграк финанслана торган заманча авыл инфраструктурасын булдыру буенча амбициоз планнар тормышка ашырыла.

РАСЛЫЙМ
Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

_______________ М.Г.Әхмәтов

«27» 02 2014 ел

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

# “2014 – 2016 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ҖИТЕН КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ”

# ВЕДОМСТВО МАКСАТЧАН ПРОГРАММАСЫ

Казан 2014

**Эчтәлек**

1. “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан программасының паспорты…........................3
2. Хәл ителеше программада карала торган проблемаларга характеристика .5
3. Җитен тармагының хәзерге торышына анализ ……………………..……..6
4. Программаның максатлары һәм бурычлары.....……………………............8
5. Программадан көтелә торган нәтиҗәләр һәм максат индикаторлары…....8
6. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы...........…………...10
7. Программаны тормышка ашыру сроклары...…………………………....11
8. Программаны тормышка ашырганнан соң ирешеләчәк социаль, икътисадый нәтиҗәләргә тасвирлама, максатка ирешүдә программаның өлешенә гомуми бәя бирү.........................……………………………...…11
9. Бюджет акчаларын нәтиҗәле сарыф итүгә бәя бирү.........………………....12
10. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү...……………..13
11. Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасына тасвирлама...14
12. Программаны тормышка ашыруның куркынычлы якларына бәя бирү…15
13. Программаны тормышка ашыру сроклары...………………………….…..15
14. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү чаралары...............................................................................................15
15. Үз эшчәнлеген авыл хуҗалыгының әлеге ярдәмче тармакларында башкаручы хуҗалыклар буенча керәчәк акчаларга фараз...................…...16

## 1. “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | - 2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы (РФ Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган)<br>- 2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы (ТР Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган) |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның максаты | Программаның максаты – үзебезнең җитен продукциясенең чимал базасын булдыру һәм җитештерүне арттыру |
| Төп бурычлар | 1 бурыч. Җитен сүсен тулаем җыюны арттыру.<br>2 бурыч. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыюны арттыру.<br>3 бурыч. Җитен сүсен эшләп чыгаруны арттыру. |
| Программада катнашучылар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы предприятиеләре. |
| Программаның төп чаралары | 1. Җитенне беренче тапкыр эшкәртү объектларын төзүгә, шул исәптән аларны реконструкцияләүгә, техник яктан яңадан җиһазлауга һәм модернизацияләүгә капиталь чыгымнар.<br>2. Җитен, киндер һәм башка сүсле культураларны сүскә күчергәндә Россия Федерациясенең эчке базарында сатучы товар җитештерүчеләргә җитен (озын сүсле җитен яки май җитене), киндер һәм башка сүсле культураларны җитештерүгә киткән чыгымнарының бер өлешен субсидияләү. |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның сроклары һәм баскычлары | 2014 – 2016 еллар |
| Программаны үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы), Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы предприятиеләре. |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Барлыгы – 419,0 миллион сум, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан –167,0 миллион сум<br>бюджеттан тыш чыганаклардан – 252,0 миллион сум<br><br>2014 ел – 116,0 миллион сум, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан – 46,0 миллион сум<br>бюджеттан тыш чыганаклардан – 70,0 миллион сум<br><br>2015 ел – 140,0 миллион сум, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан – 56,0 миллион сум<br>бюджеттан тыш чыганаклардан – 84,0 миллион сум<br><br>2016 ел – 163,0 миллион сум, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан – 65,0 миллион сум<br>бюджеттан тыш чыганаклардан– 98,0 миллион сум |
| Максат индикаторы һәм программаның күрсәткечләре (2013 елга карата 2016 ел) | 1. Җитен сүсен җыюны 3,3 мең тоннага арттыру;<br>2. Озын сүсле җитен орлыкларын җыюны 0,07 мең тоннага арттыру;<br>3. Озын сүсле җитен уңышын бер гектардан 2 центнерга арттыру;<br>4. Утырту мәйданын 700 гектарга арттыру;<br>5. Җитен сүсен эшләп чыгаруны 990 тоннага арттыру |
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр (2016 елда) | 1. Җитен сүсен тулаем җыю 5,4 мең тоннага кадәр;<br>2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю 0,12 мең тоннага кадәр;<br>3. Озын сүсле җитен уңышы бер гектардан 45 центнер;<br>4.Чәчү мәйданы 1,2 мең гектарга кадәр;<br>5. Җитен сүсен эшләп чыгару 1,62 мең тоннага кадәр. |
| Идарә итү һәм тикшереп | Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан |

| | |
|---|---|
| тору системасы | Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге җаваплы була. |

## 2. Хәл итилеше программада карала торган проблемаларга характеристика

"2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү" программасы җитен үстерү тармагын тотрыклы үстерү өчен нигез булырга тиеш, бу исә агросәнәгать комплексын үстерүнең өстенлекле максатларына ирешүдә бер баскыч булып тора.

Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы" 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган 2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы кысаларында эшләнде.

Илнең җитен чәчүче регионнарында тулаем продуктның зур өлешен туку һәм җиңел сәнәгать продукциясе тәшкил итә. Илебездә һәм дөньяда табигый сүсләргә, аеруча уникаль кулланылыш үзлекләренә ия булганга күрә җитенгә сорауның даими арта баруы туку сәнәгатен үстерүне һәм яңартуны тизләтүне таләп итә. Бу исә, үз чиратында, җитен сүсен җитештерүне арттырырга этәргеч бирәчәк. Россиянең җитен комплексын үстерүдә җитди ихтыяҗ туа, бу ил икътисадының туку, химия, азык, фармацевтика, медицина, оборона тармаклары өчен үзебезнең ышанычлы чимал базасын булдыруга этәрәчәк.

Җитен комплексын тотрыклы үстерү стратегиясе, җитештерү арту тизлегенең артуы аның эчке кулланылыш күләмнәре һәрдаим артып торганда җитен продукциясен өстәмә арттыру, шулай ук импортны алмаштыру (мамык чималы импортын киметү) хисабына тәэмин ителә ала.

Җитен комплексын тотрыклы үстерү өчен булган мөмкинлекләрне уңышлы тормышка ашыру юлындагы төп киртә - тармакның техник тәэминаты начар булу.

Җитен комплексын үстерүнең төп факторы производствога инновацион технологияләрне кертүдән гыйбарәт. Заманча технологияләрне куллану продукциянең сыйфатын дөньяви стандартлар дәрәҗәсендә булуын, җитеннән яңа төр, аеруча икътисадның башка тармакларында ихтыяҗ булган продукцияләр эшләп чыгару мөмкинлеген тәэмин итә. Бу юнәлештә заманча фәнни тикшеренүләрнең булмавы җитен комплексын инновацияле үстерү процессын тоткарлый.

Шул рәвешле җитен җитештерүне үстерүдә "йомык түгәрәк" барлыкка килә: үсеш өчен ресурсларның җитешмәве технологик артта калуга сәбәп була, шуңа күрә продукциянең сыйфаты да түбән, җитештерүдә чыгымнар да зур, импортка караганда конкуренциядә сәләтлелеге дә түбән була. Мондый

шартларда тармакның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеге шулай ук түбән дәрәҗәдә кала, бу аны үстерү өчен ресурслар җәлеп итү мөмкинлеген чикли.

“2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” программасы күрсәтелгән проблемаларны хәл итү өчен эшләнде дә.

## 3. Җитен тармагының хәзерге торышына анализ

Озын сүсле җитен – Россиядә туку сәнәгате өчен чимал бирә торган берденбер авыл хуҗалыгы культурасы. Ул зур агротехник әһәмияткә ия, тулаем чәчү әйләнешенең продуктивлыгын арттыра, күп кенә авыл хуҗалыгы культураларының кыйммәтле башлангычы булып тора. Озын сүсле җитеннең биологик үзлекләре аның туфрак-климат шартларына карата үзенчәлекле таләпләр куя, әйтик, уңай температуралар суммасына, явым-төшем күләменә, туфрак тибына. Озын сүсле җитеннең вегитация чоры 70 көннән 90 көнгә кадәр тәшкил итә, ә 18 С тан югарырак булган температуралар суммасы 700 дән алып 1227 С тәшкил итәргә тиеш. Шушы параметрлар аның Россия террриториясендә үсүен билгели дә.

Озын сүсле җитен күп көч таләп итә торган игенчелек культурасы булып тора, аның өчен җир эшкәртү өчен югары дәрәҗәдәге матди-техник чыгымнар сорала, алар исә бөртекле культураларны үстерүгә караганда 3-5 тапкыр күбрәк, шул ук вакытта ресурсларның гомуми исәбеннән 1/3 кадәр өлешен уңыш алганчы бер ел алдан сарыф итәргә кирәк һәм ягулык материалларына, минераль ашламаларга һәм үсемлекләрне яклауның химик чараларына ел саен бәяләрнең артуын исәпкә алсак, аны җитештерүнең үзкыйммәте дә үсә.

Озын сүсле җитеннең авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан кырларда үстерелүе игенчелек культураларының тулаем күтәрелешенә, чәчү әйләнешендәге барлык культураларның уңышын арттыруга ярдәм итә. Аерым алганда, турыдан-туры озын сүсле җитеннән соң соң чәчелә торган сабан культуралары күп уңыш бирәләр. Бу озын сүсле җитеннән соң җирнең чүп үләннәреннән арынуы һәм туклыклы матдәләргә баюы белән аңлатыла.

Хәзерге вакытта озын сүсле җитенне үстерүдәге төп проблемаларның берсе техника кытлыгыннан гыйбарәт. Чәчү һәм уңыш җыю вакытының бозылуы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә уңыш ягыннан шактый зыян китерәләр. Озын сүсле җитенне җыеп алгандагы төп югалтулар башка авыл хуҗалыгы культураларына караганда күбрәк. Өстәмә рәвештә җитен җыю техникасын сатып алу ихтыяҗы бар.

**2013 елда**
**Татарстан Республикасында җитен тармагы күрсәткечләре**

**1 нче таблица**

| Индикатор исеме | Исәп берәмлеге | 2013 ел |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | мең тонна | 2,1 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | мең тонна | 0,05 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | бер гектардан центнерлар | 42 |
| 4. Чәчү мәйданы | гектар | 500 |
| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | тонна | 630 |

**2014 елның 1 гыйнварына**
**агросәнәгать комплексының җитен тармагы предприятиеләрендә озын сүсле җитенне үстерү һәм җыеп алу буенча махсус авыл хуҗалыгы машиналарының, технологик җиһазларның таушалу дәрәҗәсенә анализ**

**2 нче таблица**

| Җитен орлыкчылыгы станцияләре | | Җитен заводлары | |
|---|---|---|---|
| Яше | Гомуми йомгакка карата процентларда җиһазландыру | Яше | Гомуми йомгакка карата процентларда җиһазландыру |
| 10 елга кадәр | - | 10 елга кадәр | 100% |
| 10 елдан алып 20 елга кадәр | - | 10 елдан алып 20 елга кадәр | |
| 20 елдан күбрәк | - | 20 елдан күбрәк | |

**2014 елның 1 гыйнварына**
**җитен чәчә торган хуҗалыкларда озын сүсле җитенне үстерү һәм җыеп алу буенча махсус авыл хуҗалыгы машиналарының таушалу дәрәҗәсенә анализ**

**3 нче таблица**

| Техниканың исеме | 8 елдан артык кулланыла торган техниканың булуы, гомуми исәпкә караганда процентларда |
|---|---|
| Катнаш СКЛ-3,6 чәчкече | 100 |
| Җитен җыю комбайны | 70 |
| Җитенне йолку машинасы | 50 |
| Җитен тасмаларын чорнагыч | 70 |
| Рулонга тыгызлый торган җайланма | 50 |
| Тарагыч-җыйгыч машина | 100 |
| Җитен тасмаларын әйләндерү машинасы | юк |
| Порцияләр ясау машинасы | юк |
| Рулон төягеч | 50 |
| Җитен орлыгы көшелен киптерү машинасы | юк |
| Җитен орлыгы көшелен сугу машинасы | юк |
| Орлык чистарту машинасы | юк |

## 4. Программаның максатлары һәм бурычлары

*Программаның максаты – үзебезнең җитен продукциясенең чимал базасын булдыру һәм җитештерүне арттыру.*

Куелган максатка ирешү киләчәктә тулы, нәтиҗәле үсә торган җитен комплексын булдыру өчен ышанычлы нигез булачак.

Программа максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

- җитен сүсен җыюны 3,3 мең тоннага арттыру;
- озын сүсле җитен орлыкларын җыюны 0,07 мең тоннага арттыру;
- озын сүсле җитен уңышын бер гектардан 2 центнерга арттыру;
- утырту мәйданын 700 гектарга арттыру;
- җитен сүсен эшләп чыгаруны 990 тоннага арттыру.

## 5. Программадан көтелә торган нәтиҗәләр һәм максат индикаторлары

Программа максатларына чыгарыла торган продукциянең физик күләмнәре артканда һәм технологик чылбырның барлык стадияләрендә җитештерү нәтиҗәлелеге күтәрелгәндә ирешеп була.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсе сан күрсәткечләре белән билгеләнә, алар объективлык, дөреслек, ачыклык, нисбәтлек критерийларына җавап бирәләр.

Программаның еллар буенча максат индикаторлары 4 нче таблицада бирелгән: 2014-2016 елларга “Татарстан Республикасы җитен комплексын үстерү” программасының максат индикаторлары

**4 нче таблица**

| Индикаторлар исеме | Исәп берәмлеге | План чоры – индикаторлар (күрсәткечләр) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | мең тонна | 2,1 | 3,7 | 4,4 | 5,4 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | мең тонна | 0,05 | 0,09 | 0,1 | 0,12 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | бер гектардан центнерлар | 42 | 43 | 44 | 45 |
| 4. Чәчү мәйданы | гектар | 500 | 860 | 1000 | 1200 |
| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | тонна | 630 | 1109 | 1320 | 1620 |

## Программаны тормышка ашыру чорына җитен комплексы продукциясен җитештерүнең арту темплары

**5 нче таблица**

| Индикаторлар исеме | Җитен җитештерү продукциясен җитештерүнең арту темплары, узган елга карата процентларда | | |
|---|---|---|---|
| | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | 176 | 119 | 123 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | 180 | 111 | 120 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | 102 | 102 | 102 |
| 4. Чәчү мәйданы | 172 | 116 | 120 |
| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | 176 | 119 | 123 |

## Моңа кадәрге 3 елның уртача күрсәткечләренә карата программаны тормышка ашыруның еллар буенча (табигый зурлыкларда) җитештерү арту

**6 нчы таблица**

| Индикаторлар исеме | Исәп берәмлеге | 3 ел өчен уртача күрсәткечләр (2011 - 2013 еллар) | Арту | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 3 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2014 ел | 3 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2015 ел | 3 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2016 ел |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | мең тонна | 3,1 | 0,6 | 1,3 | 2,3 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | мең тонна | 0,07 | 0,02 | 0,03 | 0,05 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | бер гектардан | 42 | 1 | 2 | 3 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | центнерл ар | | | | |
| 4. Чәчү мәйданы | гектар | 740 | 120 | 260 | 460 |
| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | тонна | 941 | 168 | 379 | 679 |

**Моңа кадәрге 3 елның уртача күрсәткечләренә карата программаны тормышка ашыруның еллар буенча процентларда җитештерү арту**

**7 нче таблица**

| Индикаторлар исеме | Исәп берәмлеге | 3 ел өчен уртача күрсәткечләр (2011 - 2013 еллар) | Арту | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 3 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2014 ел, процентларда | 3 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2014 ел, процентларда | 3 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2014 ел, процентларда |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | мең тонна | 3,1 | 119 | 141 | 174 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | мең тонна | 0,07 | 128 | 142 | 171 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | бер гектардан центнерлар | 42 | 102 | 104 | 107 |
| 4. Чәчү мәйданы | гектар | 740 | 116 | 135 | 162 |
| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | тонна | 941 | 118 | 140 | 172 |

## 6. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы

Татарстан Республикасында озын сүсле җитенне чәчү, үстерү һәм җыю белән җитен чәчү хуҗалыклары шөгыльләнә. Озын сүсле җитенне үстерү производствосы продукциясе сүскә күчергәндә җитен трестыннан, җитен саламыннан һәм озын сүсле җитеннең орлыкларыннан гыйбарәт.

Җитен үстерү зур чыгымнар таләп итә. Бу туфракны махсуслаштырылган техника белән эшкәртүгә, аерым төр ашламалар һәм гирбицидлар куллануга бәйле. Җитенне җыю өчен шулай ук махсуслаштырылган кыйммәтле комбайннар кулланыла.

Җитен җитештерүгә чыгымнарның бер өлешен субсидияләү өчен сүскә күчереп җитенне сатучы товар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан 37,5 миллион сум кирәк.

Татарстан Республикасында җитен чималын эшкәртү җитен заводларында башкарыла. Әлеге предприятиедә эшләп чыгарыла торган озын сүс туку сәнәгате предприятиеләренә һәм кыска сүс төзелеш тармагы предприятиеләренә җибәрелә. Җитен заводларын реконструкцияләү, техник һәм технологик яңадан җиһазлау гамәлләре әлеге предприятиедә җитен чималын югары сыйфатлы, европаның сыйфат стандартларына җавап бирә

торган озын сүсне, шулай ук җитеннән продукциянең, аеруча хәзерге вакытта соралган яңа ассортиментын чыгарып тирән эшкәртүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Җитен сүсен эшләп чыгаруны арттыру бурычлары Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчалары исәбеннән субсидияләр бирү юлы белән хәл ителәчәк.

Реконструкцияләү, техник һәм технологик яңадан җиһазлау гамәлләренең гомуми бәясе - 381,50 миллион сум.

## 7. Программаны тормышка ашыру сроклары

Программа чараларын үтәү 2014 – 2016 елларга өч елга каралган. Җитен тармагын төзү, реконструкцияләү, техник һәм технологик яңадан җиһазлау һәм модернизацияләү гамәлләрен башкару проект документларында каралган.

Орлыклар һәм минераль ашламалар сатып алу гамәлләре, озын сүсле җитенне үстерү эшләре сезонлы булып тора, алар иң уңай агротехник срокларда башкарылачак.

## 8. Программаны тормышка ашырганнан соң ирешеләчәк социаль, икътисадый нәтиҗәләргә тасвирлама, максатка ирешүдә программаның өлешенә гомуми бәя бирү

Җитен җитештерү тармагын үстерү нәтиҗәле технологик чылбыр булдыруны күздә тота: чимал җитештерү – беренче тапкыр эшкәртү - әзер продукция җитештерү. Бу сыйфатлы озын сүс, азыкка куллана торган һәм техник җитен маен һәм туку, азык, медицина, химия, фармацевтика, илкүләм икътисадның төзелеш тармагына караган соралган башка төр яңа продукция чыгаруны тәэмин итәчәк.

Шулай итеп, җитен комплексын тотрыклы үстерү икътисадның янәшә тармакларын ышанычлы чимал базасын булдыру өлешендә үстерүгә уңай йогынты ясаячак.

Моннан тыш, программаны тормышка ашыру яңа эш урыннары булдыруны тәэмин итәчәк, тармакка югары квалификацияле белгечләр җәлеп итәргә ярдәм итәчәк, бу авыл хуҗалыгы производствосында аеруча мөһим. Авыл хуҗалыгы производствосының һәм җитен чималын беренче тапкыр эшкәртүнең уңышлы үсүе барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым күчерүләрдән финанс чаралары керүне арттырачак.

Программаны тормышка ашыру үзебезнең үсемлекчелек продукциясенең конкуренциягә сәләтлелеген арттырырга ярдәм итәчәк, җитен җитештерүне тотрыклы үстерү һәм җитен сүсен җитештерү күләмнәрен арттыру өчен шартлар һәм алшартлар тудырачак.

Программаны тормышка ашыру кысаларында 30 яңа эш урыны булдыру, “2014-2020 елларга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” Федераль максатчан программасы кысаларында авылларда яшь белгечләргә торак төзү каралган.

### 9. Бюджет акчаларын нәтиҗәле сарыф итүгә бәя бирү

Программаның максат индикаторлары динамикасын анализлау, финанслау тулы күләмендә башкарылган очракта, җитештерү күләмнәренең шактый артуын тәэмин итәчәген күрсәтә.

Күрсәтелгән индикаторларның һәм программаны тормышка ашыруны финанслау күләмнәренең еллар буенча динамикасы 8 нче таблицада китерелә:

**Программаны тормышка ашыруның еллар буенча индикаторлар динамикасы**

**8 нче таблица**

| Күрсәткечләр | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 3 елга барлыгы: |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю, мең тонна | 2,1 | 3,7 | 4,4 | 5,4 | 13,5 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю, мең тонна | 0,05 | 0,09 | 0,1 | 0,12 | 0,31 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы, бер гектардан центнер | 42 | 43 | 44 | 45 | - |
| 4. Чәчү мәйданы, гектар | 500 | 860 | 1000 | 1200 | - |
| 5. Җитен заводларында җитен сүсен эшләп чыгару, тонна | 630 | 1109 | 1320 | 1620 | 4049 |
| 6. Җитен сүсен сатудан алган табыш миллион сум | 25,2 | 44,4 | 52,8 | 64,8 | 162,0 |
| 7. Эшләп чыгаруның еллык артуы миллион сум | - | 19,2 | 8,4 | 12,0 | 39,6 |
| 8. Эшләп чыгаруның процентларда артуы | - | 176 | 119 | 122 | - |
| 9. Эш урыннары булдыру | - | 5 | 10 | 15 | 30 |

Программаны тормышка ашыру тискәре экологик нәтиҗәләргә китерми, ул игенчелек культураларын яхшырту буенча культура – техник гамәлләр башкару юлы белән төбәкнең табигый байлыкларын торгызуга һәм саклап калуга ярдәм итәчәк.

**Тормышка ашыруны еллар буенча финанслау күләмнәренең нәтиҗәлелеге динамикасы**

**9 нчы таблица**

| Күрсәткечләр | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 3 елга барлыгы: |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Финанслау күләме, миллион сум | 116,0 | 140,0 | 163,0 | 419,0 |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю, мең тонна | 3,7 | 4,4 | 5,4 | 13,5 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю, мең тонна | 0,09 | 0,1 | 0,12 | 0,31 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы, бер гектардан центнер | 43 | 44 | 45 | - |
| 4. Чәчү мәйданы, гектар | 860 | 1000 | 1200 | - |
| 5. Җитен заводларында җитен сүсен эшләп чыгару, тонна | 1109 | 1320 | 1620 | 4049 |
| 6. Җитен сүсен сатудан алган табыш миллион сум | 44,4 | 52,8 | 64,8 | 162,0 |
| 7. нәтиҗәлелек күрсәткечләре, проценты | 16,5 | 6,0 | 7,3 | 9,4 |

## 10. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү.

Программаны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән һәм бюджеттан тыш чыганакларның акчаларын җәлеп итү хисабына башкарылачак.

Программа буенча планлаштырылган гамәлләрне тормышка ашыру өчен кирәкле акчаларның күләме орлык заводларын технологик җиһазлауга капитал салуларга экспертлар бәяләрен исәпкә алып исәпләнә.

Программа гамәлләрен финанслау күләмнәре һәм чыганаклары буенча исәп-хисаплар һәм башлангыч күрсәткечләр таблицада китерелгән.

**Программа гамәлләрен финанслауда гомуми ихтыяҗ һәм аның чыганаклары, миллион сум.**

**10 нчы таблица**

| Гамәлләр | Чыганак | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2014-2016 елларга барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| Җитен комплексына чыгымнар | Татарстан Республикасы бюджеты | 46 | 56 | 65 | 167 |
| | Бюджеттан тыш акчалар | 70 | 84 | 98 | 252 |
| | Барлыгы: | **116** | **140** | **163** | **419** |
| шул исәптән төзелешкә, реконструкцияне, техник яңадан җиһазлауны һәм модернизацияләүне | Татарстан Республикасы бюджеты | 42 | 51 | 60 | 153 |
| | Бюджеттан тыш акчалар | 64 | 76,5 | 88 | 228,5 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| кертеп, капитал чыгымлары | Барлыгы: | **106** | **127,5** | **148** | **381,5** |
| шул исәптән җитен җитештерү чыгымнарының бер өлешен субсидияләү | Татарстан Республикасы бюджеты | 4 | 5 | 5 | 14 |
| | Бюджеттан тыш акчалар | 6 | 7,5 | 10 | 23,5 |
| | Барлыгы: | **10** | **12,5** | **15** | **37,5** |

## 11. Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасына тасвирлама

Программа белән комплекслы идарә итүне һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары белән эш итүне бюджетны планлаштыру субъекты - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) башкара.

Программаны тормышка ашыру белән идарә итү системасы:

– программаны тулаем тормышка ашыру, программа максатларына, бурычларына, максат индикаторларына ирешү, программада расланган бурычлар күрсәткечләре һәм гамәлләр өчен Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге җаваплы.

– Министрлыкның структур бүлекчәләре, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының программаны тормышка ашыруда катнаша торган учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлеген координацияләүне һәм аларның программа чараларын тормышка ашыру буенча гамәлләрен килештерүне Министрлыкның икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге һәм игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башкара;

– Программаның һәр чарасын һәм, шуннан чыгып, программаны тормышка ашыруны Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге һәм кызыксынган бүлекләре башкара;

– Программа гамәлләрне финанслауны Министрлыкның финанслау бүлеге башкарачак;

– Программаның тормышка ашырылуын мониторинглауны Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге, икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге, агросәнәгать комплексын инженер-техник тәэмин итү бүлеге, Министрлыкның кадрлар бүлеге, Министрлыкның фән, мәгариф һәм инновацион технологияләр бүлеге, Министрлыкның азык-төлек базарын үстерү бүлеге, Министрлыкның инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге, Министрлыкның финанслау бүлеге, Министрлыкның предприятиеләрне реструктуризацияләү һәм агробизнесны үстерү бүлеге башкарачак;

– Программаны тормышка ашыру барышы турында хисап төзү өчен Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге, Министрлыкның икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге, Министрлыкның финанслау бүлеге, Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге җаваплы.

Татарстан Республикасы бюджетының программа чараларын тәэмин итүне финанслаудагы чыгым йөкләмәләренең хокукый нигезләре Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы арасында соңгыларын Программада катнашучылар исәбенә кертү турында килешүләр төзү нәтиҗәсендә барлыкка килә.

## 12. Программаны тормышка ашыруның куркынычлы якларына бәя бирү

Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүгә йогынты ясарга мөмкин төп куркынычлыкларга түбәндәгеләр керә:

а) Тышкы куркынычлыклар:

– дәүләт-хосусый партнерлыгы линиясе буенча инвесторлар ягыннан финанслауның, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең үз акчаларының һәм заем акчаларының җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;

– табигать-климат шартларының начар булуы;

б) Эчке куркынычлыклар:

– җитештерү һәм технология куркынычлыклары;

Программаны тормышка ашыру кысаларында куркынычлыклар белән идарә итү барлык чыганаклардан да үз вакытында кирәгенчә финанслау һәм технологик регламентларны төгәл үтәү рәвешендә башкарылырга тиеш. Энергия чыганакларына, ашламаларга, авыл өчен башка товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә нигезсез югары бәяләргә бәйле булган куркынычлыклар федераль дәрәҗәдә дәүләт тарафыннан идарә ителергә тиеш.

## 13. Программаны тормышка ашыру сроклары.

Программа 2014-2016 елларда тормышка ашырыла.

**Программа чараларын тормышка ашыру графигы**

| № п/п | Программаның бүлекләре, чаралар | Башкару өчен җаваплылар | Башкару сроклары | Эшләр күләме | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җитен комплексына чыгымнар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2014-2016 еллар | 419 млн.сум | |

## 14. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү чаралары.

1. Татарстан Республикасында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының таләпләренә туры китереп, барлык 43 муниципаль районны территориаль планлаштыру схемалары һәм авыл җирлекләренең генераль планнары эшләнгән. Генераль планнар Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең сайтларында бар.

2. Программа хуҗалык итүнең кече, урта һәм эре формаларының, кулланучылар кооперацияләренең оешмаларын да кертеп, авыл хуҗалыгы

продукциясен үстерүдән алып аны эшкәртү һәм сатуга кадәр үзара багланышын тәэмин итә.

3. Татарстан Республикасында “2014-2020 елларга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” Федераль максатчан программасы нигезендә 2014-2020 елларга республика программасы эшләнде, анда әлеге программаны тормышка ашыру урыннарында социаль; инженер һәм транспорт инфраструктураларын үстерү планнары исәпкә алына.

4. Бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында муниципаль районнарда, заманча мәгариф үзәкләрен (база мәктәпләр) төзеп һәм кирәкле мәктәп автобуслары паркын тәэмин итеп, аз комплектлы мәктәпләрнең саны киметелде, республика ел саен мәктәпкәчә балалар учреждениеләрен, гомуми практика табиблары офисларын һәм авылда заманча фельдшер-акушерлык пунктларын, спорт корылмаларын төзүне һәм реконструкцияләүне финанслый.

5. Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” программасын үтәү өчен авыл җирлегендә яшәүчеләрнең, шул исәптән яшь белгечләрнең тормыш шартларын яхшыртуга акчалар бүлеп бирү каралган. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды авыл җирендә торак төзүгә еллык 7 процентлы ипотека кредитлары бирә.

Программаны үтәү өчен 20 яңа йорт, 2000 квадрат метр төзүгә акча бүлеп бирү планлаштырыла.

6. Татарстан Республикасында авыл инфраструктурасын һәм торак төзелешен үстерүгә “2014-2020 елларга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” Федераль максатчан программасына өстәп ел саен (2014 – 2020 еллар) тагын кимендә 7 миллиард сум бүлеп бирү планлаштырыла.

7. Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджетка караганда 5-6 тапкыр артыграк финанслана торган заманча авыл инфраструктурасын булдыру буенча амбициоз планнар тормышка ашырыла.

## 15. Үз эшчәнлеген авыл хуҗалыгының әлеге ярдәмче тармакларында башкаручы хуҗалыклар буенча кирәчәк акчаларга фараз

| | Авыл хуҗалыгы предприятиесенең исеме | 2014 елга табыш фаразы мең сум |
|---|---|---|
| 1 | Саба муниципаль районының "Сабылен" ҖЧҖ | 25 280,0 |
| 2 | Мамадыш муниципаль районының “Иске тегермән фермер хуҗалыгы” ҖЧҖ | 19120,0 |
| | **Барлыгы:** | **44 400,0** |